Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы  Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсендә гражданнар җыенының
"Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсендә гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында" 2020 елның 19нчы ноябрендәге 2нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш),500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 19нчы ноябрендә Кильдураз тимер юл станциясе бистәсе гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- МТЗ-82 тракторы өчен комплектлау җиһазлары сатып алу;
- төзекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучы гражданнар исемлегенә 204 кеше кертелгән,җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 111 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча  җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенында катнашучы 111 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә  карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсендә халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы  Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляска инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү  белән килешәсезме дигән сорау буенча кабул ителгән карарны танырга һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- МТЗ-82 тракторы өчен комплектлау җиһазлары сатып алу;
- төзекләндерү;

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлегенең Кильдураз тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш)  2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- МТЗ-82 тракторы өчен комплектлау җиһазлары сатып алуга;
- төзекләндерүгә;

4.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Коштаулы авыл җирлеге Башлыгы** **Х.Ф.Сабиров**